**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 10 октябрендәге 4297 номерлы карары**

**Казан шәһәре Идел буе районының Кол Гали урамында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 164 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:160504:30;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы, Кол Гали урамы;

- билгеләү максаты: электр челтәре хуҗалыгы объекты – җирле әһәмияттәге ТП-1871 трансформатор подстанциясе урнаштыру;

- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, милек хокукы җирле әһәмияттәге ТП-1871 трансформатор подстанциясенә карата теркәлгән (2001 елның 26 декабре, №16-50.3-23.2001-1281.4).

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Гариза бирүчегә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне тәкъдим итәргә.


7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 10 октябрендәге
4297 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәре Идел буе районының Кол Гали урамында**

**ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




Масштаб 1:250
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге жир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары |
| 16:50:160504 | кадастр кварталы |
| 16:50:160504:30 | хокуклар чикләнә торган жир кишәрлегенең кадастр |